# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылы торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 30 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Иске Имән авыл җирлеге Сарысаз-Тәкермән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 20 мартындагы 2 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 нче номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 нче номерлы гражданнар җыены карарларына чараларны түбәндәгечә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

1.Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында төзелеш материаллары сатып алу һәм зират коймасын урнаштыру буенча эш өчен түләү, Сарысаз-Тәкерман торак пунктындагы зиратта хуҗалык йорты төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу);

2. Торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); Сарысаз-Тэкермән торак пунктында вак таш япмасын ремонтлау (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, вак таш ташу һәм салу, грейдирлау);

3. Электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрләрен,трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
5. Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарның вакытлыча туплану урыннарын җыю (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);»

2. Әлеге карарны Иске Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Ә.Исламова